**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлегенең Кузьминовка торак пунктында гражданнар җыены карары**

2025 елның 29 ноябре № 1

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлегенең Кузьминовка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (25.11.2024 №1049редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, 2025 елның 29 ноябрендә узган «Сез Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлегенең Федотовка торак пункты узган территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан; сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан; Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарының тол хатыннарыннан; көндезге бүлектә укучы студентлардан, хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш, 2026 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (МТЗ-82.1 тракторын тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү (ягулык-майлау материаллары сатып алу); Кузьминовка авылы территориясен коры-сары һәм чүп үләннәреннән чаптыру; Кузьминовка авылы территориясендә полосаларны минеральләштерү һәм сөрү; Кузьминовка авылы территориясендә үләнне кулдан чаптыру (килешү буенча түләү));

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Кузьминовка авылындагы юлларны кардан чистарту);

3) ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Кузьминовка авылы зиратында авария хәлендәге агачларны кисү).

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 75 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 39 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 39 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлегенең Кузьминовка торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлегенең Кузьминовка торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. «Сез Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлегенең Федотовка торак пункты узган территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан; сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан; Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарының тол хатыннарыннан; көндезге бүлектә укучы студентлардан, хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш, 2026 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (МТЗ-82.1 тракторын тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү (ягулык-майлау материаллары сатып алу); Кузьминовка авылы территориясен коры-сары һәм чүп үләннәреннән чаптыру; Кузьминовка авылы территориясендә полосаларны минеральләштерү һәм сөрү; Кузьминовка авылы территориясендә үләнне кулдан чаптыру (килешү буенча түләү));

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Кузьминовка авылындагы юлларны кардан чистарту);

3) ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Кузьминовка авылы зиратында авария хәлендәге агачларны кисү)соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң ун көн эчендә түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан, Лениногорск районы, Федотовка авылы, Совет ур., 6 й., Совет ур., 8 й. (мәдәният йорты бинасы), Кузьминовка авылы, Кооператив ур., 10 й. (авыл клубы бинасы),, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районының
Федотовка авыл җирлеге башлыгы В.И.Павлова